| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«15» июнь 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 238

Аренда түләүләрен кичектереп
тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык
субъектларына ярдәм чаралары турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яклау чаралары турында» 670-р номерлы күрсәтмәсенә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы күрсәтмәсенә таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба - муниципаль мөлкәт) арендалау шартнамәләре буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендаторлар-кече һәм урта эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгать иткән көннән алып җиде эш көне эчендә муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектерүне, 2020 елның апрель - июнендә кичектереп торылган аренда түләүләрен түләү срогы 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү;

б) арендаторлар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге карар үз көченә кергән көннән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) аренда түләүләрен түләүне кичектерү кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләре буенча бурычлары булмаган арендаторларга бирелә;

б) әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә төзелә торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель - июнь айлары өчен аренда түләвен кичектерүне һәм аны 2020 һәм (яисә) 2021 елларда аренда шартнамәсендә каралган срокларда тигез өлешләр белән түләүне, шулай ук аренда шартнамәсен вакытыннан алда өзгәндә кичектерү бирелә торган аренда түләүләре суммасын бер мәртәбә түләүне күздә тотарга тиеш.3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарның үтәлеше турында мәгълүматны 2020 елның II кварталыннан башлап хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 числосыннан да соңга калмыйча тапшыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин